СОВЕТ
СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

с.Степная
Шентала

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.06.2024 **№67**

**Советның 19.11.2014 ел, №85 Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү хакындагы Нигезләмәне раслау турында, шулай ук Кыр Шонталы авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр,чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыруы турында Карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 25 гыйнварындагы 71 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Кыр Шонталы авыл җирлеге советы карар чыгарды:

1.Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 85номерлы карарына 3 нче кушымтаның 6 нчы бүлегенең 6.2 пунктындагы 13 нче искәрмәне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"<13> Әгәр дә мондый акчаларның гомуми суммасы кешенең, аның хатыны (ире) һәм балигъ булмаган балаларының хисап чорында һәм аннан алдагы ике елдагы гомуми кеременнән артып китсә, хисап чоры өчен счетларга кергән акчалар суммасы күрсәтелә. Чит ил валютасындагы счетлар өчен суммалар Россия Банкының хисап датасына курсы буенча рубльдә күрсәтелә.".

2.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Кыр Шонталы авыл җирлеге башлыгы** **Г.Н.Кыямова**